**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"22" ноябрь 2025 ел. № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Федераль законның 45, 69 статьялар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылы территориясендә 2026 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Әтнә торак пункты урам юлларын ремонтлау һәм ябу (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Әтнә торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); балалар мәйданчыгы территориясен чистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт өчен түләү)));

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе С.Н.Порфирьев